**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 март № 140

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы; 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче; 2011 ел, 28 апрель, 347 нче; 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы; 2011 ел, 25 июль, 576 нчы; 2011 ел, 19 август, 688 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нче; 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче; 2012 ел, 1 июнь, 464 нче; 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 457 нче; 2013 ел, 26 август, 600 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4 бүлектә:

4.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмалары (төркемнәре) тәрбиячеләре ярдәмчеләренә, кече тәрбиячеләренә;»;

8 бүлектә:

8.7 нче пунктның 5 нче таблицасында:

24 нче юлның 2 графасындагы «оешмаларында» сүзләреннән соң «һәм мәктәпкәчә белем бирә торган белем бирү программалары буенча белем бирү

эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

26 нчы юлның 2 графасындагы «урта звено белгечләрен әзерләү программалары» сүзләреннән соң «һәм квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары» сүзләрен өстәргә;

8.19 нчы пунктның 9 нчы таблицасында:

«Эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен өстәмә түләү билгеләү өчен нигез» графасындагы «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләү» сүзләрен «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, мәктәпкәчә белем бирә торган белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләү» сүзләренә алыштырырга;

8.20 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.20. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә (укытучылар һәм мөгаллимнәр вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча билгеле бер чор өчен эш нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып оешмалар хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының чик мәгънәләренә ирешү тора.»;

8.33 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.33. Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә премиаль түләүләргә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фонды күләме хезмәткәрләргә (укытучылар һәм мөгаллимнәр вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча окладлар (эш хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләүгә күздә тотылган хезмәт өчен түләү фондыннан, аудиториядән тыш эшләр өчен түләүләрдән һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән кимендә 2 процент тәшкил итә.»;

9 бүлекнең 9.2 нче пунктындагы беренче абзацта «гамәлгә куючы тарафыннан» сүзләреннән соң «җитәкчегә вазыйфаи оклад билгеләү елы алдыннан килгән елның 1 гыйнвары хәленә карата» сүзләрен өстәргә»;

10 бүлектә:

10.1 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге рдеакциядә бәян итәргә:

«хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;»;

10.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларның күләмнәре һәм аларны гамәлгә ашыру шартлары күмәк шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт турындагы законнар нигезендә хезмәт шартнамәсе һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокук актлары белән билгеләнә.»;

10.4 нче пунктның беренче абзацындагы «авыр эшләрдә, хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм хезмәт шартлары башка махсус булган эшләрдә» сүзләрен «хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче» сүзләренә алыштырырга;

10.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.7. Хезмәт шартлары зарарлы һәм (яки) куркыныч булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә хезмәт шартлары нормаль булган эшләрнең төрле төрләре өчен билгеләнгән окладлар (вазыйфаи окладлар), эш хакы ставкалары белән чагыштырганда база окладының кимендә 0,04 күләмендә арттырылган күләмдә билгеләнә.»;

10.8, 10.9 нчы пунктларны төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларына һәм эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

3 бүлекнең 3.17 нче пунктындагы «хезмәткәрләргә ... эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр» сүзләрен «Белем бирү оешмаларының ... хезмәткәрләренә эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\140.doc